Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы 18 нче катнаш балалар бакчасы
муниципаль мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү бюджет учреждениясе

# Бармак уеннары

Гыйльметдинова Миләүшә Рәшит кызы,
югары квалификация категорияле
татар теле тәрбиячесе

Мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең төп бурычы – балаларны рухи яктан бай, әхлаклы, физик яктан сәламәт итеп үстерү. Бу бурычлар төрле юллар белән тормышка ашырыла. Ә шулар арасында иң әхәмиятлесе, үтемлесе һәм нәтиҗәлесе – уеннар. “Уен – баланың тормышка әзерләнү күнекмәсе ул. Уеннар балага зур файда китерәләр, алар ярдәмендә ул үзенең характерына нигез ташы булып урнашып кала торган гадәтләргә, күнекмәләргә өйрәнә, моның өстенә бу уеннар балада, гадәттә, зур канәгатьләндерү хисе уяталар” – дип язган профессор П, Ф, Лесгафт. Дөрестән дә, уеннар, бер яктан, физик тәрбия чарасы, эстетик тойгылар тәрбияләүгә ярдәм итсә, икенчедән балаларның сөйләм телләрен үстерә. Бу сыйфатларны балаларда тәрбияләүдә бармак уеннарының да роле зур.

Бармак уеннары - баланың акыл, фикер эшчәнлеген үстерүдә, дөньяны танып белергә өйрәтүдә бәя биреп бетергесез тәрбия чыганагы, чөнки әлеге уеннар аша бала әхлакый-этик кагыйдәләр белән дә таныша башлый. Бармак уеннары – өлкәннәр белән балаларның үзенчәлекле аралашу, күңел ачу чарасы. Бармак уеннарын баланың күңелен күтәрү, кәефен яхшырту, көлдертү чарасы буларак кулланабыз. Ул баланың бармак хәрәкәтләре үсешенә дә ярдәм итә. Бармак хәрәкәтләренең сөйләм үсешенә дә тәэсире зур. Бармаклар белән төрле күнегүләр ясау, аларны төрлечә хәрәкәтләндерү – баланың фикерләвен үстерүдә уңай шарт булып тора.

Галимнәр әйтүенчә, бармакларның вак мускулатурасының хәрәкәтчәнлеген үстерү буенча системалы эшләү сөйләм телен генә үстереп калмый, ә баш миенең эшчәнлеген дә яхшырта, һәм балаларның хәтере, игътибарлыгы, ишетү, күрү сәләтедә камилләшә. Ә бу рус телле балаларны татар теленә өйрәтүдә иң кирәкле сыйфатлар.

Чит телне өйрәнгән вакытта, уен кызыксыну уятучы, дәртләндерүче фактор булып тора. Уенны, төшенчәләрне үзләштерү, теманы өйрәнү, яңа материалны аңлату, ныгыту вакытында уңай технология буларак файдаланырга була. Шуңа күрә дә мин үз эшемдә бармак уеннарын еш кулланам. Балаларны туган телдә, татар телендә дөрес һәм матур сөйләшергә өйрәтүдә, аларда сәнгатьле сөйләм күнекмәсе булдыруда бармак уеннары да зур нәтиҗәләр бирә. “Бу бармак бабай...” уены балаларга бик ошый, балалар бу уенны бик яратып уйныйлар. Шөгыльләрдә уенның төрле ысулларын кулланам. Мәсәлән: “Исәнме, бабай!”, “Сау бул, бабай!”, “Бабай утыр!” “Хәерле көн, бабай!” һ.б. Бу бармак уеннары белән генә чикләнеп каллмыйм, балаларга аңлаешлы, яшь үзенчәлекләренә туры китереп, “Әй, бармаклар”, бармаклар”, **“**Яшелчәләр”, “Дусларымны сыйлыйм”, “Тату гаилә” дигән бармак уеннары иҗат иттем. Бу

бармак уеннары аша өйрәнгән сүзләр ныгытыла, сөйләм телләре үстерелә, татар теленә кызыксыну уятыла.  Бармак уеннарын уйнаганда, сүзләрне әйткәндә, бармакларны бер-бер артлы бөгеп барабыз, төрле хәрәкәтләр ясыйбыз. Тик шуны истә тотарга кирәк: бармак уеннары биш минуттан озаграк булмасын, бу баланың сөйләм функциясен стимуллаштыру өчен бик кулай вакыт санала.

Балаларның сөйләмен активлаштыру максатыннан чыгып, һәр шөгыльгә нинди дә булса уен кертелә.  Уен – ул бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз өлеше. Уеннар кешегә яшәве күңеллерәк булсын өчен кирәк. Әйе, җитез, өлгер, зирәк булып үсүе өчен төрле характердагы уеннар балалар тормышының аерылгысыз юлдашы булырга тиеш. Яшь буын тормышның төрле җайсызлыкларына бирешмәскә, уңышсызлыкларыннан җебеп төшмәскә тиеш дибез. Ә моңа яшьтән үк балаларның төрле уеннар уйнаулары аша ирешергә мөмкин.



# Әй, бармаклар, бармаклар

Әй, бармаклар, бармаклар
Йоклый, йоклый арганнар.
Йокыдан уяндылар.
Зарядкага бастылар.
Утырдылар, тордылар,
Йөгерешеп алдылар.
Утырдылар, тордылар,
Сикерешеп алдылар.
Сәламәтлек зур байлык.
Шуны дустым онытмыйк!



## Яшелчәләр

Бу бармак- кишер,
Бу бармак-суган,
Бу бармак-кыяр,
Бу бармак- кәбестә,
Бу бармак-бәрәңге.
Кәрзинемне тутырдым.
Дусларымны чакырдым.
Яшелчәләр өләштем:
Миша, мә кишер.
Саша, мә суган.
Даша, мә кыяр.
Маша, мә кәбестә.
Паша, мә бәрәңге.
Дусларыма ошады
Рәхмәт әйтеп киттеләр.



# Дусларымны сыйлыйм

Ботка басуда үскән,
Аннан өстәлгә күчкән.
Дусларымны сыйларга,
Өстәл куйдым уртага.
Тәлинкә, кашык куйдым аңа.
Салдым ботка,
Чакырдым дусларымны ашка.
Саша, Маша, кил монда!
Миша, Даша, кил монда!
Дусларымны сыйладым.
“Рәхмәт!” әйтеп киттеләр.
Рәхмәт,  рәхмәт, рәхмәт, рәхмәт рәхмәт!



# Тату гаилә

Бу өйдә бабай яши.
Бу өйдә әби яши.
Бу өйдә әти яши.
Бу өйдә әни яши.
Бу өйдә мин яшим.
Мондый тату гаилә
Булсын иде һәр өйдә.



Файдаланылган әдәбият.
К.В. Закирова Уйный-уйный үсәбез. – Мәгариф, 2005.
Мәгариф №12, 2014